СОВЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

21.10.2021 с. Введенская Слобода № 14-76

Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге бюджетының 2021 нче елның 3 нче кварталы өчен үтәлеше турында отчетны раслау турында

Введенский  Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д. В. Морозовның 2021 нче елның 3 нче кварталында авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында отчеты тыңлап һәм фикер алышкач,

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Введенский Бистәсе авыл җирлеге бюджетының 2021 нче елның 3 нче кварталы өчен үтәлеше турында отчет (№1 нче кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
3. Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советының бюджет-финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту йөкләнде.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге  башлыгы Д. В. Морозов

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге
Советының 2021 елның 21 октябрендәге
14-76 номерлы карарына
1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең 2021 нче елның 3 нче кварталында бюджет үтәлеше турында

Введенский Бистәсе авыл җирлеге бюджетының 2021 елда үтәлеше «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны алып бару һәм тормышка ашыру шартларында тормышка ашырыла.
Введенский Бистәсе авыл җирлеге бюджеты, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертеп, 9941,2 мең сум күләмендә керем буенча расланган,
Авыл җирлегенең 2011 елның 1 октябренә керем өлеше буенча 9635,9 мең сум күләмендә, 96,9% үтәлгән.
Җирлек бюджеты керемнәренең төп өлеше түбәндәге салымнар хисабына формалашты:
- физик затлар керменә салым-151,2 % ка үтәлгән (план 1000,1 мең сум булганда 1512 мең сум күләмендә үтәлгән);
- физик затлар милкенә салым-15,4% ка гына үтәлгән (план 812,1 мең сум булганда 124,7 мең сум);
- җир салымы-100,1% ка үтәлгән – 7829,1 мең сум план буенча 7819 мең сум), алардан 7646,1 мең сум оешма һәм 183 мең сум халыктан кергән.
– мөлкәтне арендага бирүдән кергән табыш-3,6 мең сум;
– түләүле хезмәтләр күрсәтүдән кергән керем-98,49 мең сум;
- бердәм авыл хуҗалыгы салымы-25,4 мең сум;
– үзара салым-45 мең сум.

Бюджетның төгәлләштерелгән чыгым өлеше (Татарстан Республикасы һәм Югары Ослан муниципаль районы бюджетларына күчерүләрне исәпкә алып) 14380,9 мең сум тәшкил итте, фактта чыгым 4933,1 мең сум күләмендә  һәм 35% үтәлде.

Чыгымнар түбәндәге максатларга башкарылган:
* идарә итүгә-1617,47 мең сум яки 63%;
* - мәдәният - 481,7 мең сум-64,7%;
* төзекләндерү - барлыгы 1372,9 мең сум – 48% - урамнарны яктырту өчен 366,6 мең сум-58 %, юлларны карап тоту-769,6 мең сум-52,2%, төзекләндерү – 219,9 мең сум-36,3%, чүп чыгару-16,9 мең сум.,
* Су суырту -74,96 мең сум яки 75%
* үзмәшгульләр өчен-10,7 мең сум – 47,7%
• коммуналь хуҗалык өлкәсендәге чараларга (шул исәптән су кудыргычлар) 1008,7 мең сумның 881,2 мең сумы тотылган, ягъни 88% ы-коммуналь хуҗалык өлкәсендә.
Үзара салым 268,8 мең сумның 238,21 мең сумы, ягъни 86,1% ы тотылган.
* Бюджетара трансфертлар 6760,9 мең сум күләмендә планлаштырылган, фактта 256 мең сум акча тотылган.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге  башлыгы                                     Д. В. Морозов